ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2024 п.г.т.Алексеевское № 365

**Гражданнарны җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32.1 статьяларына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. Гражданнарны җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.09.2021 ел, № 358 карары белән расланган Административ регламентына (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 1.2 пунктта сүзләр «унсигез яшькә җитмәгәннәргә» сүзләрен «белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шарты белән өлкән бала 18 яшькә яисә 23 яшькә җиткәнчегә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

- 2.5.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча белән тулыландырырга:

«11) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге өлкән баланы көндезге уку формасында укыту фактын раслый торган документ.»

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе Э.Н.Павловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **О.Н. Леденцов**